РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
КАЙБИЦКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЙБЫЧ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

27.05.2024 № 2-84

# РЕШЕНИЕ

Кайбыч авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының кадрлар эшен алып бару буенча аерым функцияләрне Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында килешүгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә ярашлы рәвештә, Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 мартындагы 1-44 номерлы «Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының кадрлар эшен алып бару буенча аерым функцияләрне Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында» карарының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6.1 нче пункт үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«6.1. Әлеге Килешү рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.»

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлеге Советына Буа муниципаль районы Башкарма комитеты белән өстәмә килешү төзергә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru. рәсми рәвештә басылып чыккан көннән башлап законлы көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы
Кайбыч авыл җирлеге башлыгы С.И. Нуретдинова

ТР Буа муниципаль районы
Кайбыч авыл җирлеге Советының
2024 елның 27 маендагы 2-84
номерлы карарына

1 нче кушымта

Кайбыч авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының кадрлар эшен алып бару буенча аерым функцияләрне Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында килешүгә өстәмә килешү

Буа шәһәре «____»_________ 2024 ел

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлеге Советы, Устав нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлеге башлыгы _____________________ йөзендә, алга таба «җирлек Советы» дип аталучы, бер яктан һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты турында 2021 елның 16 сентябрендәге 3-17 номерлы нигезләмә нигезендә эш итүче җитәкче __________________ йөзендә, бергә «Яклар» дип аталучылар, ул киләчәктә «район Башкарма комитеты» дип атала, икенче яктан, Кадрлар эшен алып бару буенча аерым функцияләрне тапшыру турында килешүгә түбәндәгеләр турында әлеге өстәмә килешүне төзеделәр:

1. Килешүнең 6.1 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язырга:

«6.1. Әлеге Килешү рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.

2. Әлеге өстәмә килешү рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

3. Килешүнең барлык башка пунктлары элекке редакциядә гамәлдә кала.

4. Әлеге өстәмә килешү бер үк юридик көчкә ия һәм ике экземплярда төзелгән, һәр як өчен берәр экземпляр.

Яклар имзалары

| | |
|---|---|
| Буа муниципаль районы<br>Кайбыч авыл җирлеге башлыгы | ТР Буа муниципаль районы<br>Башкарма комитеты җитәкчесе |
| _________________/ ________________ | _________________/ _______________ |